СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**«01» ноябрь 2024 ел** **№9**

**Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Яңа Кырлай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль Законның 25.1,56 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Яңа Кырлай авыл җирлеге Уставының 25 маддәсе нигезендә, Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Яңа Кырлай авыл җирлеге Яңа Кырлай авылы, Татарстан урамы, 20а йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2024 елның 12 ноябренә 11 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Яңа Кырлай авылы, Үзәк урамы, 3 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2024 елның 12 ноябренә 13 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә
3. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: Татарстан урамының 1 йортыннан 42 йортына кадәр,Яшьләр урамы, Тукай урамының 51 йортыннан 95 йортына кадәр яшәүчеләр.

2нче этап: Яшел, Дуслык,Татарстан урамының 44 йортыннан 90 йортына кадәр,Тукай урамының 1 йортыннан 47 йортына кадәр урамында яшәүчеләр

.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Яңа Кырлай авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә түләү

күләме 300 сум тәшкил итә, көндезге формада укучы студентларга, 80 яшьтән узган гражданнарга 150 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы?

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Татарстан урамы 1 йортыннан 84 йортына кадәр урам-юл челтәренең юл өслегендәге чокырларны ремонтлау).

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (насос сатып алу).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

5. Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Яңа Кырлай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Яңа Кырлай авылы, Үзәк урам, 3 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Яңа Кырлай авыл
җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров